КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1072

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 гыйнвар, 3 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «урнашкан» сүзен «теркәлгән» сүзенә алыштырырга;

1 нче пунктта «урнашкан» сүзен «теркәлгән» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә дәүләт ярдәме күрсәтү, шул исәптән күрсәтелгән продукция экспортына ярдәм итү чараларын алу мәсьәләләре буенча, граждан билгеләнешендәге югары технологияле продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы яисә гамәлгә ашырырга планлаштыручы оешмаларга мәгълүмати

һәм консультацион ярдәм күрсәтү тәртибендә:

исемендә «урнашкан» сүзен «теркәлгән» сүзенә алыштырырга;

1 нче пунктта «урнашкан» сүзен «теркәлгән» сүзенә алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Мәгълүмати һәм консультация ярдәме Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашырган оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренә күрсәтелә.

Әлеге Тәртип максатларында «оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре» термины дәүләт оборона заказы буенча продукция кайтартуларның баш үтәүчеләре («Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге 275-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пункты), дәүләт оборона заказы буенча продукция кайтартуларда катнашучы башкаручылар («Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге 275-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 4 пункты), оборона-сәнәгать комплексы оешмаларының җыелма реестрына кертелгән оешмалар (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Оборона-сәнәгать комплексы оешмаларының җыелма реестры турында» 2004 елның 20 февралендәге 96 номерлы карары) дигәнне аңлата.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин